**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Кәкре Елга авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Кәкре Елга авылы № 111-58 «07» май 2024 ел

«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Советының «Муниципаль хезмәткәрнең персональ белешмәләре белән эшләүне оештыру һәм аның шәхси эшен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Кәкре Елга авыл җирлегенең җирле үзидарә органында алып бару турындагы нигезләмә хакындагы» 06.10.2010 елнын 24 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы турында» Федераль законның 12 статьясына Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 12 декабрендәге 594-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Кәкре Елга авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Советының «Муниципаль хезмәткәрнең персональ белешмәләре белән эшләүне оештыру һәм аның шәхси эшен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Кәкре Елга авыл җирлегенең җирле үзидарә органында алып бару турындагы нигезләмә хакындагы» 06.10.2010 24 нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Преамбулада «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында» 2008 елның 17 гыйнварындагы 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы» сүзләрен «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» сүзләренә алмаштырырга.

1.2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елгап авыл җирлегенең җирле үзидарә органында муниципаль хезмәткәрнең шәхси мәгълүматлары белән эшләүне оештыру һәм аның шәхси эшен алып бару турындагы Нигезләмәдә:

а) 1.2 пунктта «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында» 2008 елның 17 гыйнварындагы 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы» сүзләрен «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2.6 пунктта «белешмәләр» сүзеннән соң «(анкетадагы белешмәләрдән тыш)» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис: И.М.Мөхәмәҗанов